Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге

Кощаково авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

14 май, 2026 ел № 15

Татарстан Республикасы Питрәч районы Кощаково авылында урнашкан җир кишәрлеге территориясен планлаштыру проектын раслау турында гавами тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощак авыл җирлегендә 2017 елның 21 августындагы 16 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән (2017 елның 14 декабрендәге 29 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 15 номерлы, 2019 елның 23 сентябрендәге 54 номерлы, 2022 елның 28 февралендәге 1 номерлы, 2023 елның 1 мартындагы 6 номерлы, 2024 елның 15 мартындагы 1 номерлы карарлар редакциясендә) карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге, Кощаково авылы адресы буенча урнашкан 16:33:080111:305, 16:33:080111:304 кадастр номерлы җир кишәрлекләре территориясен планлаштыру проектын раслау турында гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.
3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең гавами тыңлауларны оештыручыга - башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.
4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 05 июненнән дә соңга калмыйча төгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова